ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.01.2021 г.Лениногорск № 34

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2017 елның 20 ноябрендәге 1582 номерлы карары белән расланган Лениногорск муниципаль районы территориясендә дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга конкурс үткәрү тәртибенә өстәмә кертү турында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең 2021 елның 4 гыйнварындагы берләштерелгән коллегиясенең ПР-3 номерлы Беркетмәсен үтәү йөзеннән, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2017 елның 20 ноябрендәге 1582 номерлы карары белән расланган Лениногорск муниципаль районы территориясендә дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга конкурс үткәрү тәртибенә түбәндәге өстәмәне кертү турында:

1 өлешнең 1.15 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Конкурс документациясенә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмәләр тапшыруны күздә тотарга ».

2. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче З. Г. Михайлова

Л.М. Галимова
5-44-72